# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 40 и 41 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 октября 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 декабря 1992 года № 1708-XII «О Конституционном суде Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 30 октября 1998 года № 1840) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 11 – 12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I часть), № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть); 2008, № 3; 2009, № 12 (I часть); 2015, № 11 (I часть); 2016, № 3) следующие изменения:

1) часть первую статьи 40 дополнить предложениями следующего содержания: «Обращение может быть направлено в Конституционный суд Республики Татарстан в электронном виде посредством заполнения специальной формы на официальном сайте Конституционного суда Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в порядке, определяемом Регламентом Конституционного суда Республики Татарстан. В этом случае переписка с заявителем может осуществляться также в электронном виде в порядке, определяемом Регламентом Конституционного суда Республики Татарстан.»;

2) статью 41 дополнить частью четвертой следующего содержания:
«4. В случае направления обращения в электронном виде прилагаемые к нему документы и иные материалы также представляются в электронном виде, при этом приложения копий обращения, документов и иных материалов не требуется.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан  Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 октября 2018 года
№ 76-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы Конституция суды турында” Татарстан Республикасы Законының 40 һәм 41 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Конституция суды турында” 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 12 (I өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 40 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: “Мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция судына Татарстан Республикасы Конституция суды Регламенты белән билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы Конституция судының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында махсус форманы тутыру юлы белән электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин. Бу очракта мөрәҗәгать итүче белән язмача аралашу Татарстан Республикасы Конституция суды Регламенты белән билгеләнә торган тәртиптә шулай ук электрон рәвештә гамәлгә ашырылырга мөмкин.”;

2) 41 статьяга түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:
“4. Мөрәҗәгать электрон рәвештә җибәрелгән очракта, аңа кушып бирелә торган документлар һәм башка материаллар шулай ук электрон рәвештә җибәрелә, шул ук вакытта мөрәҗәгатьнең, документларның һәм башка материалларның күчермәләрен кушып бирү таләп ителми.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *

Казан, Кремль
2018 ел, 26 октябрь
№ 76-ТРЗ